Утвержден
МОБУ СОШ
им.Н.Каримова с.Кугарчи
приказом №74 от 01.03.2022 г.

# Ягез әле, әбиләр,әниләр, кызлар һәм оныклар!

**Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен.**

**Максат:**
1. Укучыларда олыларга хөрмәт тәрбияләү;
2. Укучыларның гаиләдәге олылар турында белемнәрен тирәнәйтү;
3. Бер-берләренә, гаилә әгъзаларына карата ярдәмчелек, дуслык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазланыш**: залны бизәү өчен плакатлар, стенгазеталар, балаларның дәү әниләренә багышланган рәсемнәре, фломастерлар, альбом битләре.

**Әзерлек эшләре:**
1. Программа төзү.
2. Стенгазеталар чыгару, плакатлар ясау.
3. Залны бизәү.
4. Командаларга бүленү, исемнәрен билгеләү.
5. Бүләкләр әзерләү.

**Программа:**
1. Бәйгене ачу.
2. Ярышлар.
3. Котлаулар.

Ягез әле, әниләр, әбиләр, кызлар һәм оныклар!
Зал бәйрәмчә бизәлгән, салмак кына көй агыла.
**Алып баручы:**
-Хәерле көн, безнең иң кадерле кунакларыбыз – әниләребез, әбиләребез, килгән кунаклар, балалар! Сезне барыгызны да бүгенге бәйрәм белән тәбрик итәбез.

Бәйрәмнең кайсы да тәнгә җиңеллек, рәхәтлек, җанга ял бирә. Шушы бәйрәм көне күңелегезгә шатлык, тәнегезгә сихәтлек, өегезгә иминлек алып килсен.

Әни, әнием, әнкәй! Кадерләп, назлап әйтәбез. Күңелебездәге бөтен рәхмәтне шушы гади сүзгә салабыз, һәрвакыт яныбызда булган, уңышларыбыз өчен шатланып, кайгыларыбызны уртаклашып яшәгән газиз әниебезгә дәшәбез.

Кем дөньяга кеше бүләк итә?
Ә кешегә якты дөньяны
Тойгылары кояш кебек кайнар
Эретерлек гранит каяны.
Кем күңеле тулган айдай серле,
Язлар сыман назлы, ягымлы.
Шатлыкларын башкаларга бүлә
Кайгыларга түзем, сабырлы.
Кем елмая җәйге таң аткандай
Балкып китә шундук тирә-як.
Нәфислеге гөлләр сокланырлык
Көләчлектә аңа тиңнәр юк.
Кем куллары өйне, җирне ямьли,
Изгелеге үлчәү тапкысыз.
Ул әлбәттә яшәү чыганагы,
Тормыш яме - әнкәй, әбекәй, хатын-кыз!

1 а.б. Бөтен кешелек дөньясына ямь бирүче, елмаюыгыз белән безне иркәләүче, җылы карашларыгыз белән назлаучы, акыллы фикерләрегез белән безгә ак юл күрсәтүче сөекле әниләребез, әбиләребез, дәү әниләребез!

**Анзина:**

Кояш көлеп уянды ды
Нурларын сипте мулдан.
Әбиләр килде мәктәпкә
Атлап кояшлы юлдан.
Һәр җирдә бер хикмәт көтә
Бүген гади көн түгел.
Бүген –әниләр,Әбиләр бәйрәме
Шуңа шатлана күңел.
Нинди назлы, нинди эшчән

Сезнең куллар әниләр!
Бөтен дөнья бәйрәм итә
Сезне зурлап әниләр!
**Гульзира:**
Кадерле әниләребез,
Чал чәчле дәү әниләребез!
Яшәгез сез мәңге яшь булып,
Туган йортыбызга ямь булып.
Сез булсагыз таза-сәламәт
Оныкларга булыр бик рәхәт.
Оныкларга терәк булып,
Яшәгез сез шатлыкта.
Сәламәтлек, ак бәхетләр
Юлдаш булсын картлыкта.
Картаймыйча шулай кояш кебек
Балкып торыгыз сез иртә-кич
Яхшылыкны җирдә ятмый диләр
Онытмабез сезне без һич тә.

1 а.б. Бүген без “Ягез әле, әбиләр һәм оныклар!” конкурсын уздырабыз. Әйдәгез бәйрәмдә катнашучы әниләребез, әбиләребез, һәм аларның оныкларын бирегә чакырыйк һәм алар белән танышып китик.

2 а.б. Катнашучылар белән таныштык, хәзер хөрмәтле жюри белән танышыйк!

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

**А.б.** Беренче конкурсны тәкъдим итәбез.
**1тур.**Ул **“Татлы сүзләр”** дип атала.
Кояш рәсеменең нурларына оныкларыгызны, балаларыгызны иркәләп дәшкәндә әйткән сүзләрне язырга кирәк. Әбиләр әйтәләр әниләр язалар. Оныклар искә төшерәләр.
2 а.б. Кадерле әбиләр һәм оныклар! Әйдәгез үзебезнең булганлыгыбызны, тапкырлыгыбызны мәкаль, табышмаклар

өлкәсендә күрсәтик. Мин мәкальнең яртысын әйтәм, сез дәвам итәсез.

**Әниләр өчен:**

1.Ожмахәниләрнең -.......(аяк астында)
2. Ата — беләк,.....(Ана — йөрәк.)
3. Сөйли белсәң,....( тыңлый да бел!)
4. Халык әйтсә .... (хак әйтә)
5. Ата-анасына игелек күрсәтмәгән,...(Олыгайгач үзе дә игелек күрмәс.)

**Әбиләр өчен:**

1.Акылны кешедән сора..... (үзеңнекен тот)
2. Бакча ясалмый .... (алма булмый)
3. Гыйлемсез бер яши .... (гыйлемле мең яши)
4.Сөйдергән дә тел ... (биздергән дә тел)
5. Туры сүз .... ( таш ярыр)

**Оныклар өчен:**

1. Аз сөйлә .... (күп эшлә)
2. Олыласаң олыны ..... (олыларлар үзеңне)
3. Ата-ананы тыңлаган адәм булган, ... (тыңламаган - әрәм булган)
4. Әни суккан.....( авыртмый.)
5.Әйткән сүз ... (аткан ук)

**2тур**

-Ә хәзер, уеныбызны дәвам итеп, сезнең игътибарга **табышмаклар.**

**Әбиләргә:**

1. Өй башында ярты ипи. (Ай)
2. Көч түкми, бил бөкмичә,
Кулга керми бу нәрсә.
Кулга керсә тиз ычкына,
Сизелми дә бу нәрсә. (Акча)
3.Нинди сәгать тәүлеккә ике генә мәртәбә вакытны дөрес күрсәтә? (ватык)
4. Елның нинди айлары 28 көнне үз эченә ала? (барысы да)
5. Нәрсәне йомык күз белән дә күреп була? (төшне)

**Онykларга:**

1. Бар бер үлән чокырда,
Аны таный сукыр да. (кычыткан)
2. Чыршыда бар, наратта юк,
Сылуда бар, Маратта юк. (ы хәрефе)

3. Су кайда коры була? (география картасында)
4. Кара мәче нинди ишектән керә? (ачык ишектән)
5. Бер кешенең 6 улы, аларның һәрберсенең берәр сеңлесе булган. Бу кешенең ничә баласы булган? (7)

**Әниләргә:**

1.Лампа түгел − яктырта,
Мич түгел − җылыта.*(Кояш)*

*2.* Мич эчендә кара мәче.*(Төтен)*

*3.* Үзе туңа, өйгә керми,
Үзе җылый да җылый.*(Тамчы)*

4. Үлән ашый, май ташый.(Сыер)
5. Җәй буе акыл сата,
Кышын боз булып ката.(Бака)

**3 тур:** Жюри өйгә эшне тикшерәбез**.** Причёска ясап килергә тиеш идегез. Иң оригинал прическа кемнеке булыр икән?
Кызларның чәче үрелгән, алга чыгып прическаларны күрсәтәбез. (командадан бер –ике кеше).

**4 тур:** „ Ромашка» уены.

Әйдәгез, балачактагы хыялларыбызга кайтып килик әле. Бала чакта кем генә артистларга карап сокланмаган да, кем генә алар булып кыланмаган, яки ак халат киеп, врач булып, курчакларны дәваламаган.

( Командирлар чәчәк таҗларын алалар.Анда төрле биремнәр язылган.)

- Сезгә бүген 3 яшь тулды. Әти-әниегез сезне котлап, яңа курчак бүләк итте. Әй уйнадыгыз да соң инде. Безгә дә уйнап күрсәтегез әле.
- Иртә белән баланы бакчага алып бару күренешен күрсәтегез.
- Кечкенә чакта өйрәнгән беренче җырыгызны яки шигыречегезне нәкъ шул вакыттагыча сөйләп күрсәтегез.
- Бакчадан кайтканда, әниегез белән кибеткә (магазинга) кердегез. Күзегез матур уенчыкларга төште. Шуны әниегездән алдыруыгызны күрсәтегез.
- Сезгә 4 яшь. Төне буе тешегез сызлап чыкты. Иртә белән әниегез теш врачына алып барды, сез нишләдегез?

**5 тур:** Иң өлгер гаилә.Бәрәңге әрчү.

Командадан ике кеше чыгып бәрәңге әрчетү.

**6 тур:** „ Бишек җырлары”.

Туган телгә, иксез-чиксез дөнья читлегенә алып керә торган рухи чыганакларның берсе – бишек җырлары. Безнең әниләребез бишек җырларын онытмадылар микән, кызларыбыз белә микән?! Кадерле әниләребез, кадерле кызларыбыз. Бишек җырын җырлап, бәби йоклату күренешен күрсәтегез әле.

Иң беренче сез шушы курчакларны тиз, матур итеп төрергә, аннары бишек җырларын җырлап йоклатырга тиеш (командадан 1 кеше).

**7 тур: "Тик Яулыклардан мода күрсәтү"**
Кадерле командалар сезгә 5 минут вакыт бирелә. Гаиләдән кемне дә булса мода күрсәтергә әзерлибез.Менә сезгә яулыклар.

**8тур:** Киләсе уеныбыз**"Тарелкада нәрсә?"** дип атала.
(савытлар эчендэ шикәр комы, тоз, борчак, тары, рис, он, манный ярмасы, гречка) уенга чыгучының күзе бәйләнгән килеш савыт эчендэге әйберләрне танып әйтергә тиеш.

**9 тур:" Кер юу"** керләрне башта кер бауына элү, аннары жыеп алу.Кем тизерәк эшли, тазикка кул белән тими генә , тасны аяк белән шылдырып керләрне кем беренче жыеп ала.
Кыстыргычларны бауга жыеп баралар. Вакытка жыю.

**10 тур: Сорау- жавап.** ( язып баралар)һәр берсе яза командадан яза әни, әби, онык.

1. Гаиләнең яраткан азыгы нәрсә?
2. Иң яраткан бәйрәмегез?
3. Кунаклар килгәнен яратасызмы?
4. Гаилә яратып караган телевизион тапшыру.
5. Иң беренче, иң зур оныкның туган көне кайчан?

-Ничә сорауга жаваплар туры килде? Иң күп туры килгән жаваплы команда жиңүче.

**11тур: "Шәжәрәңне беләсеңме?** Өйгә эш. Ин оригиналь шэжэрэ.

**12 тур: "Зирәкләр һәм тапкырлар конкурсы".**
Әбиләр оныкларына дәрес әзерләргә булыша. Хәзер без сезнең белемнәрегезне ачыклыйбыз.
Әбиләргә:
1. Мәктәптә эшли, балалар укыта? (укытучы)

2. Сталинның исеме? (Иосиф)
3. Сабан туе үткәрелә торган урын? (мәйдан)
4. Нәрсәне ак алтын, нәрсәне кара алтын дип атыйлар? (Мамык һәм нефть)
5. “Шүрәле” әкиятенең авторы? (Г.Тукай)
6. Мәктәптәге спорт дәресе? (физкультура)
7. Сөйләшү органы? (тел)
8. Уфа хоккей командасының исеме? (Салават Юлаев)

Оныкларга:
1. Хәбировның исеме? (Радий)
2. Дөньяда иң зур материк? (Евразия)
3. Америка акчасы? (доллар)
4. “Моабит дәфтәре”н кем язган? (М.Җәлил)
5. Әнинең әнисе? (Дәү әни)
6. Рус алфавитында ничә хәреф? (33 )
7. Башкортстанда иң зур елга? (Агидел)
8. Кеше үзенең нәрсәсен күтәрә алмый? (күләгәсен)

**13 тур:**Соңгы конкурсыбызны игълан итәбез. “Үзеңнекен тап!” дип атала. Әбиләргә күзләрен бәйләп, оныкларын танырга, ә оныкларга әбиләрен танырга кирәк.

Рәхмәт сезгә! Жюри нәтиҗәләр чыгарган арада кызлар башкаруында бию карап китик.

**А.Б.** :Хөрмәтле әбиләр! Гомерегез буе тырышып хезмәт күрсәткәнегез өчен, шушындый саф күңелле булып калганыгыз өчен, яхшы ул-кызлар тәрбияләп үстергәнегез, ә хәзер инде оныкларыгызны тәрбияләгән өчен рәхмәт сезгә! Озын гомер, сәламәтлек телибез сезгә, әбиләр! Оныкларыгызның игелеген күрегез!
Ә хәзер сүзне жюрига бирәбез.

**А.Б.:** Барлык катнашучыларга да зур рәхмәт! Әбиләрне, әниләрне, оныкларны чәй эчәргә чакырабыз! Рәхим итегез!